| | | |
|---|---|---|
| **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКТАНЫШБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** | | **СОВЕТ АКТАНЫШБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** |
| 423740, Актанышбаш авылы, Мәктәп ур., 19 йорт | | 423740, д. Актанышбаш, ул. Школьная, дом 19 |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**24 март 2025 ел** **№ 8**

**«Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Актанышбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2022 елның 27 июнендәге 6 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 28 декабрендәге 540-ФЗ номерлы Федераль законнар, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Актанышбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Актанышбаш авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Актанышбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турында, Актаныш муниципаль районы Актанышбаш авыл җирлеге Советының 2022 елның 27 июнендәге 6 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 бүлекнең 1.2 пункты. Нигезләмәләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« 1.2. Муниципаль контроль предметы (алга таба шулай ук - контроль предметы) булып:

1) контрольдә торучы затлар тарафыннан норматив хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне үтәү;

2) рөхсәт бирү документларындагы таләпләрне үтәү (гамәлгә ашыру);

3) Россия Федерациясе законнары нигезендә үтәлергә тиешле документлар таләпләрен үтәү;

4) контроль (күзәтчелек) чаралары нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган карарларны үтәү».

1.2. Нигезләмәнең 4 бүлегендәге 4.1 пунктының 1-6 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Төзекләндерү өлкәсендә контрольне гамәлгә ашырганда Башкарма комитет тарафыннан күрсәтелгән чаралар кысаларында контроль чараларның һәм контроль гамәлләрнең түбәндәге төрләре үткәрелергә мөмкин:

1) инспекция визиты контрольдә тотылучы затның (аның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләренең) яисә контроль объектының

булган (эшчәнлеген башкарган) урыны буенча тикшерү, сораштыру, язма аңлатмалар алу, инструменталь тикшерү, контрольдә тотылучы затның (аның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләренең) урнашкан (эшчәнлеген башкарган) урынында мәҗбүри таләпләр нигезендә булырга тиешле документларны таләп итү юлы белән үткәрелә.

2) производство объектын карау, тикшерү, сораштыру, язма аңлатмалар алу, документлар сорап алу, пробалар (үрнәкләр) алу, инструменталь тикшерү, сынау, экспертиза, эксперимент юлы белән аны биләүне, аннан файдалануны яисә идарә итүне гамәлгә ашыручы контрольдә тотылучы затларның теләсә кайсы санына карата рейд тикшерүе уздырыла.;

3) Документлар буенча тикшерү контроль (күзәтчелек) органы урнашкан урында үткәрелә һәм аның предметы бары тик контрольдә тотылучы затларның оештыру-хокукый формасын, хокукларын һәм бурычларын билгели торган документларындагы белешмәләрдән, шулай ук аларның эшчәнлеген гамәлгә ашырганда кулланыла торган һәм аларның контроль (күзәтчелек) органының мәҗбүри таләпләрен һәм карарларын үтәвенә бәйле документлардан гыйбарәт. Документлар буенча тикшерү барышында контроль (күзәтчелек) органы карамагында булган контрольдә тотылучы затларның документлары, алдагы контроль (күзәтчелек) чаралары нәтиҗәләре, административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау материаллары һәм әлеге контрольдә тотылучы затларга карата гамәлгә ашырылган дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль органнарының нәтиҗәләре турындагы башка документлар карала. Документлар буенча тикшерү барышында түбәндәге контроль (күзәтчелек) гамәлләре башкарылырга мөмкин: язма аңлатмалар алу, документларны таләп итү, экспертиза;

4) Күчмә тикшерү контрольдә тотылучы затның (аның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләренең) яисә контроль объектының булган (эшчәнлеген башкарган) урыны буенча карау, тикшерү, сораштыру, язма аңлатмалар алу, документларны таләп итү, пробалар (үрнәкләр) алу, инструменталь тикшерү, сынау, экспертиза, эксперимент юлы белән үткәрелә.;

5) мәҗбүри таләпләрне үтәүне күзәтү (территорияләрне төзекләндерү өлкәсендә контроль объектлары турындагы белешмәләрне, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек барышында кирә торган белешмәләрне җыю һәм анализлау юлы белән, шулай ук дәүләт һәм муниципаль мәгълүмат системаларында булган белешмәләрне, «Интернет» челтәрендәге күрсәткечләрне, шулай ук фотога һәм киного төшерү, видеога яздыру функцияләре булган хокук бозуларны теркәү техник чараларының автоматик режимда эшләүче мәгълүматлардан файдаланып алынган белешмәләрне, контрольдә торучы затлар тарафыннан күрсәтелгән белешмәләрне;

6) Күчмә тикшерү оешманың (аның филиаллары, вәкиллекләре, аерымланган структур бүлекчәләре) урнашкан (эшчәнлек алып барган) урыны, граждан эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны, контроль объектының урнашкан урыны буенча үткәрелергә мөмкин, шул ук вакытта контрольдә торучы зат белән карау, пробалар (үрнәкләр) сайлап алу, инструменталь тикшерү (видеоязмалар кулланып), сынау, экспертиза ярдәмендә хезмәттәшлек рөхсәт ителми.

Әлеге пункт белән каралган контроль чаралар һәм контроль гамәлләр төрләре күрсәтелгән чаралар кысаларында конкрет контроль объектын куркынычлылык категориясенә кертүгә карап әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасы нигезендә дифференциацияләнми.

Контроль (күзәтчелек) чараларын уздырганда аерым контроль (күзәтчелек) гамәлләрен кыскартылган күләмдә башкару бары тик 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очракларда гына башкарылырга мөмкин».

1.3. Нигезләмәнең 4 бүлегенең 4.20 пунктындагы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2025 елның 31 декабренә кадәр контрольдә тотылучы затка контроль (күзәтчелек) органының вазыйфаи затлары һәм башка вәкаләтле затлар тарафыннан

башкарыла торган гамәлләр һәм кабул ителә торган карарлар турында мәгълүмат бирү, документларны һәм белешмәләрне контрольдә тотылучы затка контроль (күзәтчелек) органы тарафыннан җибәрү әлеге Федераль законның 21 статьясы нигезендә шул исәптән почта элемтәсеннән файдаланып кәгазьдә дә гамәлгә ашырылырга мөмкин, контрольдә тотылучы затка электрон рәвештә яисә контрольдә тотылучы зат соравы буенча мәгълүмат бирү мөмкин булмаган очракта. Контроль (күзәтчелек) органы мондый гарызнамә кергән көннән алып ун эш көненнән дә артмаган вакытта контрольдә тотылучы затка күрсәтелгән документларны һәм (яисә) белешмәләрне җибәрә.»

1.4. 4.23 пунктның 1 пунктчасында «ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында күрсәтмә» сүзләреннән соң «мәҗбүри таләпләр» сүзләрен, «һәм (яисә) закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян китерүне булдырмау чараларын уздыру турында» сүзләрен төшереп калдырырга.;

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Актаныш муниципаль районы**
**Актанышбаш авыл җирлеге Советы рәисе** **Х.М.Хакимов**